МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.12.2024 Казан ш. № 02-117

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.12.2023 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына карый торган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, аныклау һәм тәгаенләштерү турындагы күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.12.2023 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына карый торган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, детальләштерү һәм билгеләү турындагы күрсәтмәләргә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 24.07.2024 ел. № 02-60, 02.12.2024 ел, №02-109 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
02.12.2024 года
№ 02-117

боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.12.2023 ел, № 02-144 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына карый торган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, детальләштерү һәм билгеләү турындагы күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр

1. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре» 2 пунктта:

а) «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.1 пунктчасында:

«01 2 13 00000 Шикәр чиренә каршы көрәш» төбәк проекты» максатчан статьясында:

-R1060 2 яшьтән 4 яшькә кадәрге 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «2 яшьтән 4 яшькә кадәрге 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25106 02 0000 150 керемнәр төренең коды буенча чагылдырыла»;

«- R1070 4 яшьтән 17 яшькә кадәрге 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәелешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «4 яшьтән 4 яшькә кадәрге 1 типтагы шикәр чиреннән интегүче балаларны глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25107 02 0000 150 керемнәр төренең коды буенча чагылдырыла»;

«01 4 12 00000 «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аңа караган оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендә башка чаралар» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешен өстәргә:

«- 54990 2024 елда мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе буенча иминиятләштерелгән затларга күрсәтелгән медицина ярдәмен финанс белән өстәмә тәэмин итү»;

б) «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.4 пунктчасында:

«04 2 0К 00000 «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» төбәк проекты» максатчан статьясында:

чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 09606 Татарстан Республикасында коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру»;

«- R688F «Новая Портовая» гидротехник корылмасын төзү» Казан шәһәре, (1 этап) 1.1.» объектын гамәлгә ашыру максатларында финанслашыла торган чыгымнар, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 29001 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

в) «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.15 пунктчасында «16 4 03 00000 «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү гамәлләре» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 67220 Югары технологияләр өлкәсендә индустриаль парклар һәм технопарклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү максатларында акционер җәмгыятьләрнең устав капиталына бюджет инвестицияләре»;

г) «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен булдыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.28 пунктчасында «35 2 02 00000 «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрен төзекләндерү» төбәк проекты» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 14180 Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасында төзекләндерелгән мохит булдыруга ярдәм итү фондына субсидия».

2. 2нче кушымтада:

а) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «04 2 0К 09605 | Коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тәэмин итү» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «04 2 0К 09606 | Татарстан Республикасында коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру»; |

б) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «16 4 03 67210 | Устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга акционер җәмгыятьләрнең устав капиталына бюджет инвестицияләре» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «16 4 03 67220 | Югары технологияләр өлкәсендә индустриаль парклар һәм технопарклар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү максатларында акционер җәмгыятьләрнең устав капиталына бюджет инвестицияләре»; |

в) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «35 2 02 14160 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә парклар һәм скверлар төзү һәм төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «35 2 02 14180 | Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасында төзекләндерелгән мохит булдыруга ярдәм итү фондына субсидия»; |

г) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «01 4 12 52580 | Диспансерлаштыру һәм профилактик медицина тикшерүләре барышында онкология авыруларын ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыручы характердагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «01 4 12 54990 | 2024 елда мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль программаларын тормышка ашыру кысаларында мәҗбүри медицина иминиятләштерүе буенча иминиятләштерелгән затларга күрсәтелгән медицина ярдәмен финанс ягыннан өстәмә тәэмин итү». |